КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2023 ел, 13 июль г.Казань № 825

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2019 ел, 4 май, 377 нче карары белән расланган Татарстан Республикасында җитештерелә торган продукцияне базарларга чыгару белән идарә итү системасында катнашучылар хезмәттәшлеге регламентына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында җитештерелә торган продукцияне базарларга чыгару белән идарә итү системасында катнашучылар хезмәттәшлеге регламентын раслау турында» 2019 ел, 4 май, 377 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2019 ел, 3 август, 643 нче; 2020 ел, 30 апрель, 352 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасында җитештерелә торган продукцияне базарларга чыгару белән идарә итү системасында катнашучылар хезмәттәшлеге регламентына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2.6 пунктта «Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары» сүзләрен «республика башкарма хакимият органнары» сүзләренә алмаштырырга;

3.1 пунктта:

3.1.1 пунктчада «Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары» сүзләрен «республика башкарма хакимият органнары» сүзләренә алмаштырырга;

3.1.5 пунктчада «Татарстан Республикасының тармак министрлыклары һәм ведомстволары» сүзләрен «тармак республика башкарма хакимият органнары» сүзләренә алмаштырырга;

3.2 пунктның 3.2.7 пунктчасында «Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнарының» сүзләрен «республика башкарма хакимият органнарының» сүзләренә алмаштырырга;

3.3 пунктның беренче һәм икенче абзацларын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.3. Республика башкарма хакимият органнары

Республика башкарма хакимият органнары түбәндәге функцияләрне башкара:»;

4.2 пунктның 4.2.1 пунктчасында «Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары» сүзләрен «республика башкарма хакимият органнары» сүзләренә алмаштырырга.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин